**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

# КАРАР

№ 268 09.09. 2020 ел.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең социаль гарантияләрне тәэмин итү, хезмәт хакын тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 1 октябреннән, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Аксубай муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 26 апрелендәге 139 номерлы карары белән урнаштырылган тәртиптә билгеләнә торган, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы бюджет өлкәсенең Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.
2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмен исәпләп чыгару өчен, әлеге карарның 1 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы бюджет өлкәсе аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесе сәркатибенең бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган вазыйфаи оклады күләмен 1,03 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.
4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Аксубай муниципаль районы сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru.
5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет Рәисе К. К. Гилманов